КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 июль г.Казань № 485

Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында

Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү юнәлешендәге тиешле дәүләт, ведомство максатчан программаларын тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан файдалана алуны тәэмин итү, шулай ук күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга
2. Дәүләт, ведомство максатчан программаларын тормышка ашыру кысаларында социаль өлкәдә эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларны җәлеп итүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Тәртип нигезендә алар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләүне башкарырга.
3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына тиешле муниципаль берәмлекләрдә үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин